КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1032

«Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның һәр катламы өчен алардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм аның карарларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип санарга:

«Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2010 ел, 19 ноябрь, 917 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 12 октябрь, 846 нчы карарының 3 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2010 ел, 19 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 18 июль, 612 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 24 июнь, 435 нче карарының 2 нче пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2010 ел, 19 ноябрь, 917 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 31 декабрь, 1098 нче карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 11 ноябрь, 1032 нче
карары белән расланды

## «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты

### I. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар

1.1. «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтүдән (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) файдаланучылар – төп гомуми белеме, урта гомуми белеме, урта һөнәри белеме, югары белеме булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар.

### II. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең хокукый нигезләре

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге законнар һәм башка норматив хокукый актлар, методик һәм инструктив документлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында белем бирү оешмасы турында мәгълүмат урнаштыру һәм аны яңарту кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 10 июлендәге 582 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген лицензияләү турында» 2013 елның 28 октябрендәге 966 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген дәүләт аккредитацияләве турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 1039 номерлы карары;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге 464 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 1199 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 гыйнварындагы 36 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «2.4.3.1186-03 нче СанПиН санитария-эпидемиология кагыйдәләрен һәм нормативларын гамәлгә кертү турында» 2003 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карары;

урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартлары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының белем бирү кластерлары кысаларында башлангыч һөнәри белем бирү системасын үстерү юлы белән икътисадның кадрларга ихтыяҗларын канәгатьләндерү чаралары турында» 2008 ел, 25 август, 600 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирүнең мәгариф оешмасы (алга таба – белем бирү оешмасы) уставы;

белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлеген җайга сала торган локаль актлары;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар, билгеләнгән кагыйдәләр һәм нормалар.

## III. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге документлар нигезендә күрсәтелә:

| Т/с | Документлар исемлеге | Документ бирүне гамәлгә ашыручы оешма | Документ бирелгән көннән аның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Россия Федерациясе гражданнары өчен | | | |
| 1. | Белем бирү оешмасына кабул итү турында гариза (рус телендә) | - | вакыты чикләнмәгән |
| 2. | Гражданның шәхесен таныклый торган документ:<br>Россия Федерациясе гражданы паспорты (14 яше тулган гражданнар өчен) | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Белем бирү турында документ һәм (яки) белем бирү турында һәм квалификация турында документ | Белем бирү турында документ һәм (яки) белем бирү турында һәм квалификация турында документ биргән мәгариф оешмасы | вакыты чикләнмәгән |
| 4. | Белем бирү оешмасына керүченең фотосурәте | - | вакыты чикләнмәгән |
| Чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар өчен | | | |
| 5. | Белем бирү оешмасына кабул итү турында гариза (рус телендә) | - | вакыты чикләнмәгән |
| 6. | Керүченең шәхесен таныклый торган документ күчермәсе яисә «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә чит ил гражданының шәхесен таныклый торган документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерациясенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| 7. | Чит ил дәүләтенең белем бирү турында документы һәм (яки) белем бирү турында һәм квалификация турында документының (документларының) (алга таба – чит ил дәүләтенең белем бирү турында документы) төп нөсхәсе, әгәр дә әлеге документ белән расланган белем бирү Россия Федерациясендә Федераль законның 107 статьясы нигезендә тиешле белем бирү дәрәҗәсендә танылса (Федераль закон белән билгеләнгән очракта – шулай ук чит ил дәүләтенең белем бирүен тану турында таныклык) | чит ил дәүләтенең белем бирү оешмалары<br><br>Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы | вакыты чикләнмәгән |
| 8. | Белем бирү турында чит ил дәүләте документының һәм аңа теркәлгән кушымтаның билгеләнгән тәртиптә таныкланган рус теленә тәрҗемәсе | нотариус | вакыты чикләнмәгән |
| 9. | Белем бирү оешмасына керүченең фотосурәте | - | вакыты чикләнмәгән |
| 10. | Чит илләрдә яшәүче ватандашларга каравын раслаучы документ күчермәсе | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | вакыты чикләнмәгән |

3.2. Керүченең әлеге тапшырылган документлар тәрҗемәсендәге фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта) Россия Федерациясендә чит ил гражданы, гражданлыгы булмаган зат шәхесен таныклый торган документта күрсәтелгән фамилиягә, исемгә һәм атасының исеменә (соңгысы – булган очракта) туры килергә тиеш.

3.3. Керүчеләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Керүчеләр укырга кабул ителгәндә тиешле вазыйфа яки белгечлек буенча хезмәт шартнамәсен яки хезмәт контрактын төзегәндә билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри алдан медицина карауларын

(тикшерүләрен) үтә торган белгечлекләр һәм әзерләү юнәлешләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 14 августындагы 697 номерлы карары белән расланган керүчеләр укырга кабул ителгәндә тиешле вазыйфа яки белгечлек буенча хезмәт шартнамәсен яки хезмәт контрактын төзегәндә билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри алдан медицина карауларын (тикшерүләрен) үтә торган белгечлекләр һәм әзерләү юнәлешләре исемлегенә керә торган белгечләр буенча укырга кергәндә мәҗбүри алдан медицина карауларын (тикшерүләрен) үтә.

3.4. Керүчеләрнең (керү сынауларын уңышлы узган керүчеләрне кертеп) саны федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән урыннар саныннан артып киткән очракта, белем бирү оешмасы керүчеләр тарафыннан тапшырылган белем бирү турындагы документларда һәм (яки) белем бирү турындагы һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләре, керүче тарафыннан кабул ителгәндә тапшырырга хокуклы мәгълүматлары булган индивидуаль уңышлар нәтиҗәләре нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясендә мәгариф турында закон» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 71 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар белән максатчан уку турында шартнамә булу нигезендә урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итүне гамәлгә ашыра

3.5. Керүчеләр тарафыннан тапшырылган белем бирү турындагы документларда һәм (яки) белем бирү турындагы һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасын керүчеләрнең үзләштерү нәтиҗәләре гомуми белем бирү предметлары буенча белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә расланган кабул итү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә исәпкә алына. Индивидуаль уңышлар нәтиҗәләре һәм (яки) максатчан укыту турында шартнамә булу керүчеләр тарафыннан тапшырылган белем бирү турындагы документларда һәм (яки) белем бирү турындагы һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасын керүчеләрнең үзләштерү нәтиҗәләре тигез булганда исәпкә алына. Индивидуаль уңышлар нәтиҗәләре һәм (яки) максатчан укыту турында шартнамә булганда, беренче чиратта, максатчан укыту турындагы шартнамә исәпкә алына.

3.6. Белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгәндә белем бирү оешмасы тарафыннан түбәндәге индивидуаль уңышлар нәтиҗәләре исәпкә алына:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күренекле сәләтләрен күрсәткән балаларны ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм аларның алга таба үсешен мониторинглау кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 17 ноябрендәге 1239 номерлы карары нигезендә олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яки) иҗади конкурсларда, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрне, фәнни (фәнни-тикшерену), инженерлык-техник, уйлап табу, иҗади, физкультура-спорт эшчәнлегенә карата сәләтләрне үстерүгә, фәнни белемнәрне, иҗади һәм спорт казанышларын пропагандалауга юнәлдерелгән чараларда җиңүче һәм бүләк алучы статусы булу;

керүченең инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» чемпионатында җиңүче һәм бүләк алучы статусы булу;

керүченең «Яшь профессионаллар (Ворлдскиллс Россия)» һөнәри берлекләрне

һәм эшче кадрларны үстерү агентлыгы» берлеге тарафыннан үткәрелә торган һөнәри осталык чемпионатында яки WorldSkills International халыкара оешмасында җиңүче һәм бүләк алучы статусы булу.

Индивидуаль уңышлар нәтиҗәләрен һәм максатчан укыту турындагы шартнамәне исәпкә алу тәртибе белем бирү оешмасы тарафыннан расланган кагыйдәләрдә белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибенә һәм шартларына карата таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге максатларда күрсәтелә:

шәхеснең урта һөнәри белем алу юлы белән һөнәри формалашуына, мәдәни һәм әхлакый үсешенә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

җәмгыятьнең урта һөнәри белемле квалификацияле хезмәт хезмәткәрләренә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучыларның гражданлык позициясе һәм хезмәт сөючәнлеген формалаштыру, җаваплылыкны, мөстәкыйльлекне һәм иҗади активлыкны үстерү.

4.2. Дәүләт хезмәте түбәндәге белем бирү оешмалары төрләрендә күрсәтелә:

һөнәри белем бирү оешмалары;

урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыручы югары белем бирә торган мәгариф оешмалары.

Белем бирү оешмасының үз структурасында, тормышка ашырыла торган мәгариф программаларының дәрәҗәсен, төрен һәм юнәлешен, укучыларның уку формаларын һәм булу режимын исәпкә алып, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган төрле структур бүлекчәләре (филиаллар, вәкиллекләр, бүлекләр, факультетлар, институтлар, үзәкләр, кафедралар, әзерлек бүлекләре һәм курслары, фәнни-тикшеренү, методик һәм укыту-методик бүлекчәләре, лабораторияләр, конструкторлык бюролары, уку-укыту һәм укыту-җитештерү остаханәләре, клиникалар, уку-укыту-тәҗрибә хуҗалыклары, уку-укыту полигоннары, практиканың уку-укыту базалары, уку-укыту-демонстрация үзәкләре, уку-укыту театрлары, күргәзмә заллары, уку-укыту цирк манежлары, уку-укыту бию һәм опера студияләре, уку-укыту концерт заллары, сәнгать-иҗат остаханәләре, китапханәләр, музейлар, спорт клублары, студентлар спорт клублары, мәктәп спорт клублары, тулай тораклар, мохтаҗ белем алучыларны социаль адаптацияләүне һәм тернәкләндерүне тәэмин итә торган психологик һәм социаль-педагогик хезмәтләр һәм белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән күздә тотылган башка структур бүлекчәләр) булырга мөмкин.

4.3. Белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

төп гомуми белем бирү базасында, урта гомуми белем алып, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру;

урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру.

4.4. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру түбәндәге белем алу формаларында гамәлгә ашырыла:

көндезге;

көндезге-читтән торып.

4.5. Белем бирү оешмасында төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирү базасында көндезге формада белем алу буенча квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча уку вакытлары урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты белән билгеләнә торган аларны үзләштерүнең норматив вакытлары нигезендә билгеләнә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында түбәндәге чаралар үткәрелә:

төп белем бирү программалары структурасына (шул исәптән төп белем бирү программасының мәҗбүри өлеше һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган өлеш нисбәтенә) һәм аларның күләменә; төп белем бирү программаларын тормышка ашыру шартларына, шул исәптән кадрлар, финанс, матди-техник һәм башка шартларга; төп белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә карата таләпләрне билгели торган урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру;

өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру;

һөнәри белем бирүнең төп программаларын тормышка ашыру.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә белем бирү оешмалары:

квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләүнең инновацион программаларын булдыруга юнәлдерелгән методик эш алып бара;

Татарстан Республикасында һөнәри белем бирүнең өстенлекле юнәлешләрен үстерүгә ярдәм күрсәтә.

4.8. Белем бирү оешмасында дәүләт хезмәтенең эчтәлеге квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары белән билгеләнә, алар уку-укыту планы, календарь уку-укыту графигы, уку-укыту предметларының эшче программалары, курслар, дисциплиналар (модульләр), башка компонентлар, шулай ук бәяләү һәм методик материаллар рәвешендә тәкъдим ителә.

4.9. Белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәткәндә уку елы 1 сентябрьдән башлана һәм билгеле бер һөнәр һәм белем алу формасы буенча уку-укыту планы нигезендә тәмамлана. Уку елы башлану вакыты белем бирү оешмасы тарафыннан көндезге-читтән торып уку формасы буенча иң күбе бер айга күчерелергә мөмкин.

Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын үзләштерү барышында белем алучыларга бирелә торган каникулларның дәвамлылыгы бер ел урта һөнәри белем алганда кышкы чорда – кимендә ике атна һәм уку елында – кимендә ун атна, шул исәптән бер елдан күбрәк урта һөнәри белем алганда кышкы чорда кимендә ике атна тәшкил итә.

4.10. Белем алучыларның уку-укыту эшчәнлеге уку дәресләрен (дәрес, практик дәрес, лаборатор дәрес, консультация, лекция, семинар), мөстәкыйль эш, практиканы, шулай ук уку-укыту планында билгеләнгән башка төр уку эшчәнлеген күздә тота.

Аудитория дәресләренең барлык төрләре өчен академик сәгать 45 минут дәвамлылыгында билгеләнә.

4.11. Уку төркемендә белем алучыларның саны иң күбе 25 кеше тәшкил итә. Белем бирү оешмасының үзенчәлегеннән чыгып, уку-укыту дәресләре һәм практика

белем бирү оешмасы тарафыннан аз санлы белем алучылар төркемнәре һәм аерым белем алучылар белән, шулай ук төркемне төркемчәләргә бүлеп үткәрелергә мөмкин. Белем бирү оешмасы лекцияләр рәвешендә уку дәресләрен үткәргәндә белем алучылар төркемнәрен берләштерергә хокуклы.

Уку-укыту төркемендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларның саны 15 кешегә кадәр билгеләнә.

4.12. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларның укуы башка укучылар белән бергә, шулай ук аерым сыйныфларда, төркемнәрдә оештырылырга мөмкин.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны югары квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча укыту белем бирү оешмасы тарафыннан мондый укучыларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен һәм сәламәтлекләренең хәлен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Белем бирү оешмалары тарафыннан сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга урта һөнәри белем алу өчен махсус шартлар тудырылырга тиеш.

4.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланганда белем алучының, аудитория һәм аудиториядән тыш уку йөкләнешенең барлык төрләрен кертеп, бер атнага белем алучының уку йөкләнеше күләмнәре урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә билгеләнә.

4.14. Белем бирү оешмасы белем алучыларны бәяләү системасын, арадаш аттестацияләү формаларын, тәртибен һәм дәвамлылыгын сайлап алуны мөстәкыйль башкара. Белем алучыларның белемнәрен агымдагы тикшерү һәм арадаш аттестациясен үткәрү турындагы нигезләмә белем бирү оешмасы тарафыннан раслана.

Белем алучыларны арадаш аттестацияләү барышында имтиханнар саны уку елында – 8 имтиханнан, ә зачетлар саны 10 нан артмаска тиеш. Бу санга физик культура һәм факультатив уку курслары, дисциплиналар (модульләр) буенча имтиханнар һәм зачетлар керми. Индивидуаль уку планы нигезендә белем алганда белем алучыларны арадаш аттестацияләү барышында имтиханнар һәм зачетлар саны әлеге уку-укыту планы белән билгеләнә.

4.15. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын үзләштерү мәҗбүри булган йомгаклау аттестациясе белән тәмамлана.

Академик бурычы булмаган, уку-укыту планын яки индивидуаль уку-укыту планын тулы күләмдә үтәгән белем алучылар – йомгаклау аттестациясен, ә урта һөнәри белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган мәгариф программалары буенча урта һөнәри белем алганда дәүләт йомгаклау аттестациясен үтә.

4.16. Урта һөнәри белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән затларга урта һөнәри белем бирүнең һәм урта һөнәри белем бирүнең тиешле һөнәре буенча квалификация алуны раслый торган урта һөнәри белем бирү турында диплом бирелә.

Йомгаклау аттестациясен үтмәгән яки йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләр алган затларга, шулай ук квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасының бер өлешен үзләштергән һәм (яки) белем бирү оешмасыннан чыгарылган затларга белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль

билгеләнә торган үрнәк буенча уку яки уку чоры турында белешмә кәгазе бирелә.

4.17. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта гомуми белеме булмаган белем алучылар дәүләт йомгаклау аттестациясен үтәргә хокуклы; аның тарафыннан урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары үзләштереп бетерелә һәм, аны уңышлы үткәндә, аларга урта гомуми белем бирү турында аттестат бирелә. Әлеге белем алучылар дәүләт йомгаклау аттестациясен бушлай уза.

4.18. Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга – 18 яше тулганга кадәр ике яки бер ата-анасы үлгән, шулай ук бер яки ике ата-анасының кайгыртуыннан мәхрүм калган 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге затларга дәүләт хезмәте күрсәтү тулысынча дәүләт тәэмин итүе нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.19. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча белем алучыга студентлар билеты һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләүнең белем бирү программаларын үзләштерүче студентның зачет кенәгәсе бирелә.

4.20. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланганда белем алучы белем бирү оешмасы китапханәләреннән, мәгълүмат ресурсларыннан, уку-укыту, социаль-көнкүреш, дәвалау һәм башка бүлекчәләре хезмәте күрсәтүләрдән белем бирү оешмасы уставында билгеләнгән тәртиптә түләүсез файдаланырга хокуклы.

4.21. Көндезге формада белем алучылар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнә торган күләмнәрдә стипендияләр белән тәэмин ителә.

4.22. Торак мәйданга мохтаҗ белем алучылар белем бирү оешмасының тиешле торак фонды булганда тулай торак урыннары белән тәэмин ителә.

4.23. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча белем алучыларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

4.24. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатылырга мөмкин:

белем алучы яки балигъ булмаган белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) инициативасы буенча, шул исәптән белем бирү программасын үзләштерүне дәвам итү өчен белем алучыны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка белем бирү оешмасына күчергән очракта;

15 яше тулган белем алучыга карата дисциплинар җәза чарасы буларак укудан туктатуны кулланган очракта, белем алучы тарафыннан һөнәри белем бирү программасы буенча мондый белем бирү программасын намуслы үзләштерү һәм уку-укыту планын үтәү буенча йөкләмләр үтәлмәгән очракта, шулай ук белем алучының гаебе буенча аны законсыз рәвештә белем бирү оешмасына кабул итүгә китергән белем бирү оешмасына кабул итү тәртибен бозу билгеләнгән очракта, белем бирү оешмасы инициативасы буенча;

белем алучының яки балигъ булмаган белем алучы ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ихтыярына һәм белем бирү оешмасына бәйле булмаган вакыйгалар буенча, шул исәптән белем бирү оешмасы ябылган очракта.

## V. Дәүләт хезмәте күрсәтүне матди-техник яктан тәэмин итүгә карата таләпләр

5.1. Белем бирү оешмасы үзенә беркетелгән һәм (яки) милек хокукында үзенеке булган биналарны, корылмаларны, мөлкәтне, җиһазны һәм куллану, социаль, мәдәни һәм башка билгеләнештәге бүтән мөлкәтне бу территориядә гамәлдәге булган нормативлар белән билгеләнә торган дәрәҗәдән ким булмаган дәрәҗәдә тотуны тәэмин итә.

5.2. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмасының дәүләт таләпләрен тормышка ашыруны тәэмин итә торган һәм гамәлдәге санитар-техник нормаларга туры килә торган матди-техник базасы булырга тиеш.

5.3. Белем бирү оешмасының төп һәм өстәмә бина урыннары мәйданнарының күләмнәре тормышка ашырыла торган белем бирү программаларына, бер тапкыр сыйдыруга, укыту барышы технологияләренә, инженерлык-техник җайланмага, кирәкле җиһаз белән җиһазландырылуга бәйле рәвештә, санитария һәм төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләре нигезендә кабул ителә.

5.4. Белем бирү оешмасы уку-укыту кабинетларын һәм лабораторияләрен, уку-укыту һәм укыту-җитештерү остаханәләрен тормышка ашырыла торган квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары нигезендә булдыра.

5.5. Белем бирү оешмасы санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары, стандартлар, техник шартлар, башка норматив документлар таләпләренә җавап бирә торган җиһаз, аппаратура һәм приборлар белән җиһазландырылырга тиеш.

5.6. Уку-укыту практикасы белем бирү оешмасының уку-укыту, укыту-җитештерү остаханәләрендә, лабораторияләрендә, укыту-тәҗрибә хуҗалыкларында, укыту полигоннарында, уку-укыту практика базаларында һәм башка структур бүлекчәләрендә йә тиешле юнәлештәге белем бирү программасы буенча эшчәнлек алып баручы оешма (алга таба – оешма) һәм белем бирү оешмасы арасындагы шартнамәләр нигезендә оешмаларда махсус җиһазландырылган бина урыннарында үткәрелә.

## VI. Дәүләт хезмәте күрсәтү иминлегенә карата таләпләр

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүче белем бирү оешмалары законнар белән билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлергә һәм аларның түбәндәге документлары булырга тиеш:

дәүләт аккредитациясе турында таныклык;

Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу кертү турында таныклык;

тормышка ашырыла торган белем бирү программаларына лицензияләр.

6.2. Белем бирү оешмасының бина урыннар «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары, санитария-эпидемиология нормалары таләпләренә туры килергә тиеш.

6.3. Махсус җиһаз, приборлар һәм аппаратура катгый рәвештә билгеләнеше буенча, эксплуатацияләү документлары нигезендә файдаланылырга, техник яктан төзек хәлдә булырга тиеш.

Төзек булмаган махсус җиһаз, приборлар һәм аппаратуралар алыштырылырга, ремонтланырга (ремонт ясарга мөмкин булганда) яки эксплуатацияләүдән алынырга тиеш.

6.4. Белем бирү оешмасы үз компетенциясенә кертелгән функцияләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен, уку планы нигезендә белем бирү программаларын тулы күләмдә тормышка ашырмаган өчен, үз чыгарылыш укучылары белеменең сыйфаты өчен, шулай ук белем бирү оешмасының белем алучылары, хезмәткәрләре тормышы һәм сәламәтлеге өчен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә. Белем алучыларның, балигъ булмаган белем алучылар ата-аналарының (законлы вәкилләренең) белем алуга хокукларын һәм белем бирү турындагы законнар белән күздә тотылган хокукларын һәм ирекләрен бозган яки законсыз чикләгән, белем бирү эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне бозган өчен белем бирү оешмасы һәм аның вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә административ җавап бирә.

6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче белем бирү оешмасының эшчәнлеге туктатылган очракта, белем бирү оешмасы караган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, ата-аналар (законлы вәкилләр) ризалыгы белән, укучыларны шундый дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы башка белем бирү оешмаларына күчерүне тәэмин итә.

## VII. Файдаланучылар өчен дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә торган таләпләр

7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны белем бирү оешмасына кабул итү күләме һәм структурасы дәүләт йөкләмәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә билгеләнә.

7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны белем бирү оешмаларына кабул итү тәртибе Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

7.3. Белем бирү оешмасы Россия Федерациясе законнарына, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан билгеләнгән белем бирү оешмаларына кабул итү тәртибенә һәм гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә торган һәм белем бирү оешмасы уставында беркетелгән кабул итү кагыйдәләренә каршы килми торган өлештә ел саен кабул итү кагыйдәләрен эшли һәм раслый.

7.4. Хезмәт һәм ялның иң уңайлы режимын булдыру максатларында, белем бирү оешмасының дәресләр расписаниесе белем алучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм билгеләнгән санитария-гигиена нормаларын исәпкә алып төзелә, шул ук вакытта хезмәт күрсәтүче оешмаларда дәресләр 8 сәгать 00 минуттан иртәрәк башланмаска, 20 сәгать 00 минуттан соңрак тәгәлләнмәскә тиеш.

7.5. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар белем алганда махсус дәреслекләр һәм уку әсбаплары, башка уку әдәбияты, шулай ук сурдотәрҗемәчеләр һәм тифлосурдотәрҗемәчеләр хезмәтләре түләүсез күрсәтелә.

Әлеге социаль ярдәм күрсәтү чарасы – Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе (федераль бюджет акчасы исәбеннән белем алучы инвалидлардан тыш). Федераль бюджет акчасы исәбеннән белем алучы инвалидлар өчен бу чараны тәэмин итү Россия Федерациясенең чыгым йөкләмәсе булып тора.

## VIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүне кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

8.1. Белем бирү оешмасы квалификацияле белгечләр белән штат расписаниесе һәм уку-укыту төркемнәре саны нигезендә тәэмин ителергә тиеш. Белем бирү оешмасы персоналын туплау тәртибе аның уставы белән регламентлана.

8.2. Урта һөнәри яки югары белемле һәм квалификация буенча белешмә сүзлекләрдә һәм (яки) һөнәри стандартларда күрсәтелгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар педагог эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукына ия.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә түбәндәге затларга педагог эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт ителми:

закон көченә кергән суд карары нигезендә педагог эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгән;

шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз рәвештә госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), шәхеснең җенси иминлегенә һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлагына, дәүләтнең конституция төзелеше нигезләренә һәм иминлегенә, кешелек тынычлыгына һәм иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен җинаять кылуга тартылган (тернәкләндерү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), хөкемгә тартылучы яки хөкемгә тартылган (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы өченче өлешендә билгеләнгән һәм бу пунктның сигезенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш);

уйлап эшләнелгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки бетмәгән хөкемгә тартылучы;

Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән расланган исемлек белән күздә тотылган авырулары булган.

Бу пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән, шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз рәвештә госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлагына, дәүләтнең конституция төзелеше нигезләренә һәм иминлегенә, кешелек тынычлыгына һәм иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы аз авырлыкта җинаятьләр һәм уртача авырлыкта җинаятьләр кылган өчен хөкемгә тартылганнар арасындагы затларга һәм акламый торган нигезләр буенча бу җинаятьләрне кылуда гаепләү туктатылган затларга, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика

комиссиясенең аларны педагог эшчәнлегенә рөхсәт итү турында карары булган очракта, педагог эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт ителә.

8.3. Белем бирү хезмәткәрләре уставны, эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә, һөнәри этиканы төгәл үтәргә, аларга йөкләнгән вазыйфаларны сыйфатлы башкарырга тиеш.

Педагог хезмәткәрләре белем бирү барышының югары нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә, үз квалификациясен күтәрү белән системалы рәвештә шөгыльләнергә тиеш.

8.4. Педагог хезмәткәрләре югары сыйфатлы белем бирү барышын тәэмин итә торган белем бирү алымнарын һәм чараларын сайларга хокуклы.

8.5. Педагог хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү Россия Федерациясе законнары нигезендә өч елга кимендә бер тапкыр өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда белем бирү һәм (яки) стажировка үтү юлы белән оештырыла.

## IX. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итүгә карата таләпләр

9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү һәм белем бирү оешмасы турында мәгълүмат «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы таләпләренә туры килергә тиеш.

9.2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма укырга керүчене һәм (яки) аның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) үз уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе, дәүләт аккредитациясе турындагы таныклык, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, белем алучыларның хокукларын һәм йөкләмәләрен җайга сала торган башка документлар белән таныштырырга тиеш.

Белем бирү оешмалары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирелгән ачык һәм һәркем өчен файдалану мөмкинлеге булган мәгълүмат ресурсларын формалаштыра һәм аларны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән белем бирү оешмасының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән мондый ресурслардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итә.

9.3. Документларны кабул итә башлаганга кадәр кабул итү комиссиясе белем бирү оешмасының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендында түбәндәге мәгълүматны урнаштыра:

9.3.1. 1 марттан да соңга калмыйча:

белем бирү оешмасына кабул итү кагыйдәләре;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамәләр буенча укырга кабул итү шартлары;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы лицензиясе нигезендә белем бирү оешмасы укырга кабул итүне игълан итә торган һөнәрләр исемлеге (белем алу формаларын (көндезге, көндезге-читтән торып) күрсәтеп);

укырга керү өчен кирәкле белем (төп гомуми яки урта гомуми белем) булу дәрәҗәсенә карата таләпләр;

гаризаларны һәм кирәкле документларны электрон рәвештә кабул итү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

укырга керүченең мәҗбүри алдан медицина каравын (тикшерүен) үтәргә кирәклеге (кирәклеге булмау) турында мәгълүмат; әлеге тикшерүне үтәргә кирәк булган очракта – табиб-белгечләр исемлеген, лаборатория һәм функциональ тикшеренүләр исемлеген, медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган гомуми һәм өстәмә билгеләр исемлеген күрсәтеп;

9.3.2. 1 июньнән дә соңга калмыйча:

һәр һөнәр буенча, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча укырга кабул итү урыннарының гомуми саны;

һәр һөнәр буенча, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанслана торган урыннар саны;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр нигезендә һәр һөнәр буенча, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча урыннар саны;

тулай торак булу һәм тулай торакларда башка шәһәрдән укырга керүчеләр өчен бүлеп бирелә торган урыннар саны турында мәгълүмат;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә үрнәге.

9.4. Документлар кабул итү чорында кабул итү комиссиясе көн саен белем бирү оешмасының рәсми сайтында һәм кабул итү комиссиясенең мәгълүмат стендында һәр белгечлек буенча, белем алу формалары (көндезге, көндезге-читтән торып) билгеләп, тапшырылган гаризаларның саны турында мәгълүмат урнаштыра.

Кабул итү комиссиясе белем бирү оешмасына кабул итүгә бәйле мөрәҗәгатьләргә җавап бирү өчен махсус телефон линияләре һәм белем бирү оешмасының рәсми сайтында бүлек эшләвен тәэмин итә.

9.5. Белем бирү оешмасы дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыга дәүләт хезмәте күрсәтү турында дөрес мәгълүматны үз вакытында бирергә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга тиеш. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат составына түбәндәгеләр кертелергә тиеш:

бу Стандарт;

белем бирү оешмасында уку алып барыла торган урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартлары исемнәре;

дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның хезмәт күрсәтү сыйфатына йогынты ясау мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның оешма хезмәткәрләре белән коммуникация чаралары турында мәгълүматлар;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына файдаланучы бәя бирү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

хезмәтләр күрсәтү кыйммәте күләмен күрсәтеп, түләүле хезмәтләр күрсәтү турында мәгълүмат;

хезмәтләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары;

белем бирү оешмасының – хезмәт күрсәтүләрне башкаручының гарантия йөкләмәләре.

9.6. Мәгълүмат бирү ысулы һәм тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

## X. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Стандартның III бүлеге нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яки берничә документ булмау;

медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр булу.

10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

белем алучы мөһим булмаган сәбәпләр аркасында белгечлек буенча уку планын билгеләнгән вакытта үтәмәү;

белем алучы белем бирү оешмасы уставы белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәмәү;

белем алучы эчке тәртип кагыйдәләрен бозу.

## XI. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы

11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасын үзләштерү һәм урта һөнәри белем бирү турында диплом алу.

11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатының индикаторлары:

| Күрсәткечнең (индикаторның) исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Күрсәткечнең (индикаторның) иң чик мәгънәсе | Үлчәү коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучыларның гомуми санында беренче тапкыр эш эзләгән, эшсезләр дип билгеләнгән тәртиптә танылган, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучылар өлеше | процент | $\frac{В_б}{В} \times 100$ %,<br>монда:<br>$В_б$ – беренче тапкыр эш эзләгән, эшсезләр дип билгеләнгән тәртиптә танылган, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучылар саны;<br>В – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 3 | 9 |
| 2. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучыларның гомуми санында урта һөнәри белем бирү турында диплом алган чыгарылыш белем алучылар өлеше | процент | $\frac{В_д}{В} \times 100$ %,<br>монда:<br>$В_д$ – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган, урта һөнәри белем бирү турында диплом алган белем алучылар саны;<br>В – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 8 |
| 3. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча белем алучылар тарафыннан белемнәр, күнекмәләр һәм осталыклар үзләштерү коэффициенты | процент | $\frac{А}{В} \times 100$ %,<br>монда:<br>А – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасын «яхшы»га һәм «бик яхшы»га үзләштергән белем алучылар саны; | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 80 | 7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | В – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча чыгарылган белем алучыларның гомуми саны | | | |
| 4. Хезмәт күрсәтүнең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы белән канәгать булган дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | процент | $\frac{\frac{О_к + О_д}{2}}{О_{общ}} \times 100\ \%,$<br>монда:<br>$О_к$ – хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатыннан канәгать булган сораштырылучылар саны;<br>$О_д$ – хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлегеннән канәгать булган сораштырылучылар саны;<br>$О_{общ}$ – сораштырылучыларның гомуми саны | дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларны сораштырулар нәтиҗәләре буенча | 90 | 9 |
| 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның нигезләнгән шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Ж_о}{Ж} \times 100\ \%,$<br>монда:<br>$Ж_о$ – хисап чорында кергән дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның нигезләнгән шикаятьләре саны;<br>Ж – хисап чорында кергән дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар шикаятьләренең гомуми саны | дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның шикаятьләрен һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүматларны анализлау | 0 | 9 |
| 6. Һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында укуын дәвам иткән чыгарылыш белем алучылар санының чагыштырма авырлыгы | процент | $\frac{В_у}{В} \times 100\ \%,$<br>монда:<br>$В_у$ – һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында укуын дәвам иткән чыгарылыш белем алучылар саны;<br>В – чыгарылыш белем алучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 10 | 8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. Укып бетергәннән соң кимендә ике ел эчендә эшкә урнашкан һәм һөнәре буенча эшләгән чыгарылыш белем алучылар санының чагыштырма авырлыгы | процент | $\frac{В_{тр} + В_{у}}{В - В_{вс}} \times 100$ %,<br>монда:<br>$В_{тр}$ – укып бетергәннән соң кимендә ике ел эчендә эшкә урнашкан һәм һөнәре буенча эшләгән чыгарылыш белем алучылар саны;<br>$В_{у}$ – белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң бер ел эчендә көндезге уку формасында киләсе дәрәҗәдә укуын дәвам иткән чыгарылыш белем алучылар саны;<br>$В_{вс}$ – Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакырылган чыгарылыш белем алучылар саны;<br>В – чыгарылыш белем алучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 80 | 9 |

## XII. Бу Стандартны үтәмәүгә карата шикаять бирү, аны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) белем бирү оешмасына язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Белем бирү оешмасы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр белем бирү оешмасын гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына бирелә.

12.2. Белем бирү оешмасы, белем бирү оешмасының җитәкчесе, белем бирү оешмасының хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, белем бирү оешмасының рәсми сайтын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыны шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять аларны карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгән көннән 15 эш көне эчендә, ә белем бирү оешмасы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучының документларын кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять биргән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча законнар нигезендә карар кабул ителә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыга язма рәвештә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучының теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыга бирелә торган җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, белем бирү оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучы тарафыннан кылынырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат китерелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелә алмый дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыга бирелә торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат (хезмәткәр) булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## XIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе

13.1. Теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге белем бирү оешмасы тарафыннан лицензиядә каралган шартларның үтәлешен тикшерүдә тоту лицензия биргән мәгариф белән идарә итү буенча дәүләт органы тарафыннан тәэмин ителә. Бу шартлар бозылган очракта, лицензия кире алынырга тиеш.

13.2. Дәүләт аттестация хезмәте дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмасына белем бирүнең сыйфатына һәм (яки) белем бирүнең урта һөнәри белем бирү буенча тиешле федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килмәвенә карата рекламация җибәрергә мөмкин.

13.3. Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XIV. Дәүләт хезмәтен түләүле яки түләүсез күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Әгәр дә мондый дәрәҗәдәге белем беренче тапкыр алынса, гражданнар белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез нигезендә файдаланырга хокуклы.